| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ КУГУНУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУНЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октября 2024г. № 106

О Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Куныр авыл җирлеге башлыгының, Куныр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 102нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 22 март 72нче номерлы, 2024 елның 19 июле 99нче номерлы үзгәрешләре белән)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 нче сентябреннән 829 нчы номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкалэтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2024 елның 29 нчы октябре 288 нче номерлы карары» һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба - Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 2018 елның 17 декабрендәге 195 нче номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «13323» санын «13990» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү Тәртибенең ( 1нче кушымта) 1 пунктында «18260»

санын «19173» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 01.01.2025 елында үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Куныр авыл җирлеге башлыгы Р.О.Егоров